| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| 422054, Республика Татарстан,<br>Сабинский район,с.Большой Шинар,<br>ул. Кооперативная,дом 36<br>тел. (84362) 41-2-11 | 422054, Татарстан Республикасы,<br>Саба районы,Олы Шыңар авылы,<br>Кооператив урамы, 36 йорт<br>тел. (84362) 41-2-11 |

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
05.07.2023 №17

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 22 нче июлендә кабул ителгән 14нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Саба районы Прокуратурасының 26.06.2023 №02-08-02-2023/476-23-20920031 протесты нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Олы Шыңар авыл җирлеге Советы тарафыннан 22.07.2009 елда кабул ителгән «Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» 14нче номерлы карары белән расланган “Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмә”гә (алга таба текст буенча - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.1. пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа бишенче абзац белән тулыландырырга:

« - Россия Федерациясе Кораллы кечләрен, башка гаскәрләрне, хәрби формалаштыру һәм органнарны тыныч вакыттан сугыш вакытына күчерү буенча чараларны тәэмин итү ечен, мобилизация чорында һәм аларның кирәкле дәрәҗәдә комплектлануын тәэмин итү ечен запаста булган хәрби-укытылган гражданнарның кирәкле санын әзерләү буенча планлы эш алып бару.»;

1.2. Нигезләмәнең III бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

« III. Функцияләр .

3.1 Беренчел хәрби исәп документларында булган мәгълүматларны җыюны, саклауны һәм эшкәртүне оештыру һәм тәэмин итү максатыннан, хәрби-хисәп хезмәткәре:

а) запаста булган гражданнарны һәм хәрби хезмәтка чакырылырга тиешле, аларның территориясендә яшәүче яки (өч айдан артык срокка) булган гражданнарны беренчел хәрби исәпкә ала;

б) эчке эшләр органнары белән берлектә үз территориясендә яшәүче яки (өч айдан артык срокка) булган һәм хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнарны ачыклый;

в) үз территориясендә булган оешмаларны исәпкә ала һәм аларда хәрби исәп-хисап алып баруны контрольда тота:

г) беренчел хәрби исәп документларын машина белән язу һәм электрон төрләрдә алып бара һәм саклый.

3.2. Беренчел хәрби исәп документларындагы мәгълүматларны актуаль хәлдә тоту һәм хәрби исәп документларындагы мәгълүматларны актуаль хәлдә тотуны тәэмин итү максатыннан, хәрби-хисап хезмәткәре:

а) беренчел хәрби исәп документларын тиешле муниципаль берәмлек хәрби комиссариатларның һәм оешмаларның хәрби исәп документлары белән елына 1 тапкырдан да сирәгрәк булмаган күләмдә чагыштыра;

б) беренчел хәрби исәп документларындагы мәгълүматларга үз вакытында узгәрешләр кертә һәм ике атна эчендә хәрби комиссариатларга кертелгән узгәрешләр турында хәбәр итә;

в) оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән хәрби исәп, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларын аңлата, аларның үтәлешен контрольдә тота, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен жаваплылык турында хәбәр итә;

г) ике атна эчендә муниципаль берәмлекләрнең тиешле Хәрби комиссариатларына оешмаларның вазыйфаи затлары һәм гражданнарның хәрби исәп, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларын үтәмәү очраклары турында мәгълүмат тапшыра.

Беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырганда хәрби-хисәп хезмәткәре «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ shinar адреслары буенча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов